**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы**
**Иске Мажын авыл җирлеге Советы карары**

**«06» октябрь 2021** **№ 1**

Җирле салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар суммаларын түләттерүгә һәм юкка чыгаруга өметсез дип тану өчен нигезләр билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 2019 елның 2 апрелендәге №ММВ-7-8/164@ «Түләтүгә өметсез дип танылган пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча недоимканы һәм бурычларны бетерү тәртибен һәм недоимканы, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану шартларын раслаучы документлар исемлеген раслау турында»гы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иске Мажын авыл җирлеге Советы,

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Физик затларның җир салымы һәм физик затлар милкенә салым, пенялар һәм штрафлар буенча (алга таба-бурыч)недоимканы түләттерүгә һәм юкка чыгаруга ышанычсыз дип тану өчен түбәндәге нигезләрне билгеләргә:

1.1. вафат булган физик затларда бурычлары булу, барлыкка килгән вакыттан алып өч елдан артык вакыт узганнан соң;

1.2. психик бозылулары булган физик затларда бурычлар булу, аларны суд тәртибендә эшкә сәләтсез дип танудан соң;

1.3. картлар (ветераннар) йортларында яши торган бурычы булган физик затларда

1.4. ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында булган физик затларның бурычлары булу-иректән мәхрүм итү урыннарында булган чорда суд карары нигезендә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләр нигезендә түләтүгә өметсез дип танылган бурыч суммаларын исәптән төшерү Иске Мажын авыл җирлеге Советы карары һәм Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иске Мажын авыл җирлеге башкарма комитеты документлары (үлем турында белешмә, эшкә сәләтсезлек турында белешмә һ.б.) һәм салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе нигезендә башкарыла.

3. Бурычларны бетерү, агымдагы елның 1 мартына булган бурычлар буенча, календарь ел дәвамында бер тапкыр башкарыла.

4. 10 календарь көн эчендә бурычны бетерү турында карар салым органына җибәрелә.

5. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Минзәлә муниципаль районы
Иске Мажын авыл җирлеге башлыгы Э. Р. Шәймәрданов

Совет СТАРОМАЗИНСКОГО сельского поселения
ОГРН 1021605552781
ИНН 1628002837